РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ
«ОТДЕЛ ОБРАЗОВАНИЯ»

Переулок Больничный, дом 6,
пгт. Рыбная Слобода, 422650

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

«МӘГАРИФ БҮЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ

Хастаханә тыкрыгы, 6 нчы йорт,
Балык Бистәсе штп., 422650

Тел.: (8-84361) 2-21-92, факс: (8-84361) 2-21-26. E-mail: sloboda.ege@rambler.ru, sloboda.filial@mail.ru

**Балык Бистәсе муниципаль районы “Яңа Арыш урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Галимова Гүзәлия Наил кызын татар теле һәм әдәбияты укытучыларының “Туган тел” Бөтенрәсәй мастер- класс бәйгесенә тәкъдим итү кәгазе**

Галимова Гүзәлия Наил кызы 1979 нчы елның 28 нче ноябрендә Балык Бистәсе районы Яңа Арыш авылында туган. Югары белемле, КДПУ ның татар теле һәм әдәбияты бүлеген “Татар теле һәм әдәбияты” белгечлеге буенча 2002 нче елда тәмамлаган.

Эш урыны: Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш урта гомуми белем бирү мәктәбе татар теле һәм әдәбияты укытучысы.

Квалификация категориясе: 1

Эш стажы: 20 ел

Эш шартлары: 2018-2019 нче уку елында - 5, 6, 7, 8, 11 нче сыйныфларда татар теле һәм татар әдәбияты дәресләре укыта.

Галимова Г.Н. педагогик хезмәт нәтиҗәләре өчен түбәндәге мактау кәгазьләре белән бүләкләнде:

- Татар мәгрифәтчесе Мөхлисә Буби исемендәге IV Республика педагогик укулары грамотасы, 2016;
- “Ел укытучысы- 2016” бәйгесе лауреатына Балык Бистәсе муниципаль районы Мактау грамотасы (Боерык №47 о/д от 05.02.2016);
- “Тамчы-шоу” телевизион интеллектуаль уены белән актив хезмәттәшлек өчен ТНВ каналының Мактау грамотасы, 2016;
- “Сөйләм телен үстерү дәресләрендә фразеологизмнарның роле”- республикакүләм семинар-стажировка кысаларында чыгыш. Сертификат, 2016;
- “Актуализация знаний - как один из этапов современного урока в условиях ФГОС ООО” вебинарда катнашучы сертификаты, 2016;
- “Яңа технологияләрнең шәхесне формалаштырудагы роле” республикакүләм семинарында мастер-класс, сертификат 2017;
- “Ел сыйныф җитәкчесе-2018” бәйгесе лауреатына Балык Бистәсе муниципаль районы Мактау грамотасы (Боерык №40 о/д от 29.01.2018);
- “Тамчы-шоу” телевизион интеллектуаль уены белән актив хезмәттәшлек өчен ТНВ каналының Мактау грамотасы, 2018.
- Республика олимпиадасының муниципаль этабында татар теле һәм әдәбият фәннәреннән һәр ел саен җиңүче, призерлар әзерләгән өчен Балык Бистәсе муниципаль районы Мактау грамотасы (Боерык №539 о/д от 16.08.2018)

- “Ел укытучысы- 2019” бәйгесендә актив катнашуы өчен Балык Бистәсе муниципаль районы Мактау грамотасы (Боерык №853 о/д от 19.12.2018);
- “Татарча диктант” акциясен чын мәгънәсендә дөньякүләм чара итеп оештырга ярдәм иткән өчен Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы рәисе В.Р.Шәйхразиевның рәхмәт хаты, Казан-2018.

Галимова Гүзәлия Наил кызы үзенең педагогик эшчәнлегендә алдынгы педагогик технологияләргә таянып эшли. Семинар һәм конференцияләрдә чыгыш ясый, укытучыларның профессиональ бәйгеләрендә осталыгын күрсәтә. Ул “Ел укытучысы” Бөтенрәсәй бәйгесенең муниципаль этабында 2016 елда лауреат булды. Шулай ук “Ел сыйныф җитәкчесе” Бөтенроссия бәйгесенең муниципаль этабында 2018 елда лауреат исемен яулады.

Укучыларын фәнни һәм иҗади эшкә кызыксындыра белә, республика күләмендә чаралар: олимпиада, фәнни-гамәли конференцияләрдә алар уңышлы чыгыш ясыйлар.

Уку-укыту, тәрбия өлкәсендә укытучы түбәндәге бурычларны хәл итү өстендә эшли: рухи яктан бай һәм киңкырлы, конкурентлыкка ия шәхес тәрбияләү; үзүсеш һәм үзтәрбияләнү өчен шартлар тудыру; шәфкатьлелек хисләре тәрбияләү, укучының уңай үсешенә ирешү максатыннан гаилә һәм мәктәп бердәмлеген ныгыту.

Дәресләрдә алган белемнәрен укучылар проект, эзләнү эше аша киңәйтәләр. Укытучы төрле әдәби кичәләр, викториналар үткәрә. Сыйныфтан тыш эшләрне татар теленә мәхәббәт тәрбияләү максаты белән оештыра. Гореф-гадәт, йолаларны саклау, буыннан-буынга тапшыру эшләрен алып бара.

Галимова Гүзәлия Наил кызы - ата- аналар, укытучылар, укучылар арасында ихтирамга лаеклы шәхес.

Балык Бистәсе муниципаль районы мәгариф идарәсе Галимова Гүзәлия Наил кызының эшчәнлеген уңай бәяли. Мөгаллимәне татар теле һәм әдәбияты укытучыларының Бөтенрәсәй күләмендә үткәрелә торган “Туган тел” мастер-класс бәйгесенең республика этабына тәкъдим итә.

Балык Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының “Мәгариф
бүлеге” муниципаль казна
учреждениесы җитәкчесе: И.М.Садиков